

# *Исәнме,*
# *балалар бакчасы!*

***Әти-әниләр өчен кулланма(6-7 яшь)***

***Тот яхшы тәрбиядә***

Яңгырларга бирешми,
Ләкин онытма шуны:
Пычрак йөртү килешми,
Бик ярата ул суны,
Бернинди дым сеңдерми,
Кояшны һәм сабынны,
Тузганлыгын сиздерми.
Чыныкканда, салкынны.
Бөгәрләнми бөртек тә,
Аннан башка беркем дә
Ә һава яхшы үтә.
Яши алмый бер көн дә.
Йөз ел яшә, барыбер
Тот яхшы тәрбиядә,
Гомер буена җитә.
Нәрсә соң ул, әйт, әйдә?! (Тән тиресе) ***Заһирә Гомәрова***

| | |
|---|---|
| **Мәкальләр**<br>*Бит күрке — күз, тел күрке — сүз.<br>* Сөйдергән дә тел, биздергән дә тел.<br>* Сүз бирсәң — үтә.<br>* Ничек эндәшсәң, шулай ишетерсең.<br>* Аз сөйлә, күп бел. | |
| Яттан өйрәнү өчен<br>***Мәктәп***<br>Җәй үтеп, көз җиткәч үк,<br>Инде башланды дәресләр,<br>Мәктәп күзен ачты тагын;<br>Инде мәктәп җанлана;<br>Ялтырап китте урамнар,<br>Нинди шат, нинди бәхетле<br>Басты нур төрле ягын...<br>Монда кергән һәр бала!<br>Нәҗип Думави | |

| | |
|---|---|
| **Җырлы-биюле уен «Наза».**<br>Балалар, парлашып, бер-бер артлы тезелеп басалар. Бер бала парсыз, ул уенчылар каршысына чыгып баса.<br>Наза дигән кыз баланың<br>Бөрлегәне түгелгән.<br>«Наза» дигән уенны без<br>Уйныйбыз чын күңелдән.<br>Кушымта: Наза, Наза,<br>Наза – матур кыз бала.<br>Наза тырыш, уңган бала,<br>Зирәк, акыллы бала. | |
| Хәрәкәтле уеннар<br>**Күз бәйләш**<br>Уйнаучылар түгәрәкләнеп тезеләләр, түгәрәкнең уртасында ике бала басып тора. Аларның берсенең күзен бәйлиләр, ә икенчесенә кечкенә кыңгырау бирәләр. Беренче бала кыңгырау тавышы буенча иптәшен тотарга тырыша, әђ икенчесе ничек булса да тоттырмаска тырыша. Ул тотылганнан соң, түгәрәк уртасына башка балалар керәләр.<br>**Узышчылар**<br>Балалар парлашып, бер-бер артлы тезелеп басалар. Уйна-учылардан 20–25 м ераклыкта сызык үткәрелә яисә бу урын флаглар белән билгеләнә. Уйнаучылар барысы бергә: «Бер, ике, өч!» – дип кычкыралар. Шуннан соң беренче булып басып торган ике бала флагларга кадәр йөгереп барып, кире йөгереп әйләнеп кайталар. Икесе дә бер-берсен узарга тырыша. Кире әйләнеп кайткан балалар артка басалар, аннан соң икенче пар йөгерә. | |



# *Өлкәннәргә хөрмәт*

*Әти-әниләр өчен кулланма (6-7 яшь)*

**_Оекбаш_**

Кыш көне салкын булса да,
Сарык йоны җылы була.
Һич туңмый минем аяк.
Бар бит тагын шунысы —
Җылыта аны дәү әни
Күчкән аңа дәү әнием
Бәйләп биргән йон оек.
Кулларының җылысы.

Рафис Корбан

| | |
|---|---|
| **Мәкальләр**<br><br>Картлар сүзен капчыкка сал, яшьләрнекен янчыкка сал.<br>Олының сүзен оекка кыстыр.<br>Картлар сүзен кар басмас.<br>Олыласаң олыны, олыларлар үзеңне. | |
| ***Яулык алыш уены***<br>Бу уен күбесенчә кыз балалар тарафыннан уйнала. Кызлар бер урынга түгәрәкләнеп басалар да бер кешене яулык җыючы итеп сайлап куялар. Ул уртага чыгып баса да:<br>Талым, талым, талчыбык,<br>Уртасында бал чыбык,<br>Ал яулык, гөл яулык,<br>Бир син миңа бер яулык, —<br>дип такмаклый-такмаклый, барлык кызлардан да яулык җыеп чыга. Җыеп бетергәч, яулык хуҗаларына берәм-берәм җәза бирелә. Җәзадан соң уен тагын яңадан башлана. | |

| | |
|---|---|
| **Хәрәкәтле уен «Бабай һәм оныклар».** Бер бала – бабай, калганнары – оныклар; бабай өйдә уты- ра, ә оныклар өйдән читтәрәк нәрсә эшләячәкләре турында сөйләшәләр. Мәсәлән: бакчада җир казыдык, оекбаш бәйләдек, кер юдык һ.б. Аннары бабай янына киләләр, бабай алардан: «Сез кайда булдыгыз?»- дип сорый. Балалар: «өйдә», «урманда», «бак- чада» һ.б. дип җавап бирәләр. Бабай: «Сез анда нишләдегез?»- ди. Балалар бергәләп бертөрле хәрәкәт белән нәрсә эшләгәннәрен күрсәтәләр. Бабай белергә тиеш. Дөрес җавап әйтелгәч, балалар йөгерәләр, бабай аларны куа. Беренче тотылган бала бабай була. | |



# Бакчадагы һөнәрләр

*Әти-әниләр өчен кулланма (6-7 яшь)*

## Гөлсем апа

Гөлсем апаны күрерсез,
Бакчабызга килсәгез,
- Менә безнең тәрбияче
Гөлсем апа, — диярбез.
- Кайнамаган салкын суны
Эчмәгез! — ди ул безгә,
Аның сүзен онытмыйбыз,
Кайткач та өебезгә.

— Үскәннәрем, — ди ул безгә,
Чиста булсын сөлгегез.
Бервакытта да авырмас
Сезнең матур күзегез.
Порошок белән юабыз,
Тешебезне агартып,
— Шикәр төсле булган ич, — ди
Гөлсем апа, яратып.

Әминә Бикчәнтәева

| | |
|---|---|
| **Мәкальләр**<br>*Хезмәт төбе — хәзинә.<br>* Эше барның ашы бар.<br>* Тирләп эшләсәң, тәмләп ашарсың.<br>* Бакча ясамый, алма булмый.<br>* Эшләп ашасаң, һәр ризык балдай татлы була.<br>* Агачны яфрак бизәсә, кешене хезмәт бизи.<br>* Тырышкан табар, ташка кадак кагар.<br>* Биш әйткәнче, бер эшлә.<br>* Сүзең белән мактанма — эшең белән мактан. | |
| ***Башмакчы***<br>Балалар түгәрәк ясап басалар. Өлкәннәрдән берәү уенны оештыручы була. Ул, кулына бер башмак алып (уйнаучы балаларның аяк размерыннан башмак зуррак булырга тиеш), уртага баса. Җырлый:<br>Төрле һөнәр беләбез, Матур итеп тегәбез;<br>Асыл төсле җепләр белән<br>Башмак башын чигәбез.<br>Балалар аңа каршы, түгәрәк буйлап йөреп, җыр җырлыйлар:<br>Әй башмакчы, башмакчы,<br>Үзең — оста такмакчы.<br>Син җырлама такмагың,<br>Бир кияргә башмагың.<br>Балалар җырлап бетергәч, алып баручы башмакны 2 бала арасына куя һәм аларның иңнәренә кагыла. 2 бала икесе ике якка түгәрәк буйлап йөгереп китәләр. Кем беренче килеп җитә, шул башмакны кия. Ул «башмакчы» була. Уен яңадан башлана. | |



# ***Күз***

***Әти-әниләр өчен кулланма (6-7 яшь)***

**Көз житте**

Киң болыннарда,
Урман-кырларда
Агачлар, гөлләр
Кибеп сулдылар.
Уйсу жирләрдә,
Елга, күлләрдә
Күзге салкыннан
Сулар тундылар.

Көннәр суынды,
Чишмәләр тынды.
Безне калдырып,
Кошлар да китте.
Кошлар шикелле
Бергә гөр килеп,
Мәктәптә укыр
Вакытлар житте

Муса Жәлил.

## Мәкальләр

Көз бай булма, яз бай бул.

Көз кычкыра: «Уңдырам»,— дип, ә яз әйтә: «Тукта әле, мин нәрсә әйтермен»,— дип.

Көзге көн ул бала кебек: әле көлә, әле елый.

Күз өчен яз яхшы, авыз өчен көз яхшы.

Көзге көннән язгы төн яхшы.

Көзге юлга кием ал, язгы юлга азык ал.

## Сүзле уен «Көз»

- И балалар, күрегез,
Тышта әнә килде көз.
- Әйе, әйе, күрәбез,
Көз килгәнен беләбез.
- Я әйтегез, сөйләгез,
Ничек килә икән көз?
- Кошлар оча
көньякка,
Канат кагып еракка.

Аюлар өн казыды,
Бик тирән итеп базны.
Балыклар да тындылар,
Су төбенә чумдылар.
Агачлар ялангачлар,
Җилләрдә чайкалалар.
Тик безгә күңелле көз,
Без бакчага йөрибез.

## Җырлы-биюле уен «Куш кулым».

Урман буйларына менәм
Урман буе ямьлегә.
Бир кулыңны,
Мин дә бирәм,
Дус булырга мәңгегә.
Менә сиңа уң кулым,
Менә сиңа сул кулым.

Уң кулым да, сул кулым,
Менә сиңа куш кулым.
Алма бакчасына кереп,
Алма ашыйсым килә.
Син алмасы, мин чәчәге
Булып яшисем килә.



# *Минем өй, минем бистә, минем республика*

***Әти-әниләр өчен кулланма (6-7 яшь)***

**Шәһәр төзим**

Мин яңа шәһәр төзим,
Ул шундый шәһәр булыр:
Чәчәкле урамнарда
Машина чабып торыр.
Шәһәрнең уртасыннан
Зур елга агып торыр.
Йөзеп арган көймәгә
Дулкыннар кагып торыр.
Бу шәһәрдә кошларга
Таш атмаслар малайлар,
Усал малайлар күреп
Шаккатмаслар агайлар.

Абыйлар һәм апалар
Бик-бик тату яшәрләр,
Бер-берсенә һәрвакыт
«Исәнме!» дип дәшәрләр.
Төзүче булыр әти,
Әни булыр тегүче.
Абый белән без икәү —
Машиналар йөртүче.
Мин яңа шәһәр төзим,
Ул шундый шәһәр булыр:
Чәчәкләр, агачларга
Тамчы сибелеп торыр.

Чәчәкләр биеп торыр,
Гел «рәхмәт!» диеп торыр.

Рәшит Бәшәр

**Табышмаклар**

* Көн-төн йөри,
Урыныннан китә алмый.
(Сәгать)
* Почмакта бер суык кыш,
Исеме аның... (суыткыч).
* Төймәсенә басу белән
Бәйли зәңгәр яулыгын.
Аш пешерә, чәй кайната —
Күрсәтә уңганлыгын.
(Газ плитәсе)

*Сөйләп бирә тел белән,
Сүзе китә юл белән,
Юлы агач башында.
(Телефон)
* Үзе бер әрҗә,
Бөтен дөньяны
Күрсәтә. (Телевизор)
* Аяксыз, кулсыз
Өй саклый.
(Йозак)

***«Тимербай» уены.***

Уйнаучылар, кулга-кул тотынышып, түгәрәкләнәләр. Бер бала уртага чыга. Түгәрәктәге балалар хор белән такмак әйтеп әйләнәләр:

\- Тимербайның биш
баласы,
Бар да матур, күз карасы;
Агым суда коендылар,
Ап-ак итеп юындылар,
Өс-башларын киенделәр,
Рәхәтенә тиенделәр.
Тезелеп кайтып киттеләр,
Ашамадылар, эчмәделәр,
Бер-берсенә караштылар
– Менә шулай эшләделәр.

Такмак бетүгә уртадагы бала нинди дә булса берәр хәрәкәт ясый. Түгәрәктәге балалар шунда ук аның кыланышларын ка- батлыйлар. Кем кабатлый алмый, аны уртага кертәләр һәм уен яңадан башлана.



# *Куркынычсызлык кагыйдәләре*

*Әти-әниләр өчен кулланма (6-7 яшь)*

**Батыр кызчык**

Күрче, әнә бер кызчык
Ә кызчык бер курыкмый,
Песиен ничек тоткан
Тып итеп аяк тибә,
Маэмай аңа тимәсен,
Бармак яный маэмайга:
Яклаучысыз димәсен.
Син минем дуска тимә!
Һау-һаулап маэмай өрә,
Бигрәк тә нәни кызчык,
Уенда ни — кем белә?..
Ә үзе батыр ничек!
Йә эләктереп алса?
Яздым әле шул хакта,
Йә селтәп җиргә салса?
Улым, дим, син дә ишет. *Бикә Рәхимова*

## Мәкальләр

*Аюдан курыксаң, урманга барма,
*Бүредән курыксаң, сарык асрама.
* Ике куянны берьюлы кумыйлар.
* Юлда йөрергә дә акыл кирәк.
* Урау булса да, юл яхшы.
* Юлга чыксаң, азыгың үзең белән булсын.

## Табышмаклар

* Авызы юк, борыны юк,
Тик бар аның өч күзе.
Урамдагы хәрәкәтне
Көйләп торадыр үзе.
(Светофор)
* Башыбыз бар, гәүдәбез бар,
Юк кул, аякларыбыз.
Балалар тотса куркабыз —
Яман шул якларыбыз.
(Шырпы)
* Пожар турында ишеткәч,
Сигнал бирергә ашык.
Янгын гел көчәя бара,
Туктатып булмый ич һич.
Су гына сүндермәс аны,
Кирәк шул... (ут сүндергеч).
* Автомобиль, трамвайдан
Саклан, димен, бик сак бул!
Уйный торган урын түгел
Машиналар йөргән... (юл).

| | |
|---|---|
| **Кем ераграк ыргыта?**<br>Уйнаучылар 2 яки 3 рәткә тезеләләр. Мәйданның киңлегенә карап, һәрбер рәђттә 7–8 кеше була. Беренче рәттә басып торучыларның кулларында туп. Алар, тәрбияченең «Башлагыз!» дигән сигналына карап, кулларындагы тупларын ыргыталар. Ераграк ыргыткан бала мактала. Тупны ыргыткан балалар туплары артыннан йөгереп баралар да аны артларында торучыларга бирәләр. | |
| **Куяннар һәм аучылар**<br>Санамыш ярдәмендәике бала «аучы» итеп билгеләнә. Калган балалар «куяннар» булалар. Аучылар мәйданчык-ның төрле урыннарында таралып йөриләр. Куяннар мәй-данчык буйлап йөгерешәләр, сикерәләр. Тәрбияченең «Аучылар!» дип әйтүенә, куяннар теләсә нинди торышта катып калалар һәм шул килеш селкенмичә торалар. Аучылар туктап калган урыннарыннан куяннарга аталар – аларга кар йомарламнары ыргыталар. Аучы кемгә кар-ны тидерсә, шуны, үзе белән алып китеп, билгеле бер урынга (читлеккә) утырта. Уен 2–3 тапкыр кабатланган-нан соң, һәр аучының ничә куян атканлыгы санала. Ан-нан соң, яңа «аучылар» сайланып, уен яңадан кабатлана. | |



# *Кеше һәм предметлар дөньясы*

## *Әти-әниләр өчен кулланма (6-7 яшь)*

**Кәгазь**

Без укый торган китаплар,
без яза торган дәфтәрләр,
без карый торган альбомнар
башта — агач булганнар.
Яфрак ярып, җилдә шаулап,
Җирдә басып торганнар.

Аннан аларны екканнар,
чапканнар да кискәннәр...
Машиналардан үткәреп,
юка кәгазь иткәннәр.
Алдымда — чиста ак кәгазь,
Нинди агачтан икән?

Каеннанмы, нараттанмы,
әллә усактан микән?
Аның урынына яңаны
кемдер утырткан микән?..
...Уйлап тордым да ясадым
кәгазьгә бер имәнне.

Ясадым мин имәннең
шәбен — менә дигәнне!
Очы күккә тигәнне,
мәңге үсеп торырлыкны.
— Кош оя корырлыкны.
Күргән кеше шатлансын.
Кәгазьдә генә булса да,
тагын бер агач артсын!

*Равил Фәйзуллин*

## Мәкальләр

* Китап — белем чишмәсе.
* Китап галим — телсез мөгаллим.
* Китапның белмәгәне юк.
* Китапсыз өй — ишәк абзары.
* Үзеңнең надан икәнеңне беләсең килсә, күп китап укы.

## Табышмаклар

* Кышын да, җәен дә бертөсле.
(Чыршы, нарат)

* Ап-ак күлмәген кигән,
Күлмәгенә тап тигән.
(Каен)

* Озын, яшел — түтәлдә,
Сары, тозлы — кисмәктә.
(Кыяр)

* Үсеп утыра бер чүлмәк,
Өстенә кигән йөз күлмәк.
(Кәбестә)

* Нинди агач җилсез шаулый? (Усак)

* Алсу битле кыз үсте,
Кызарып, җиргә төште.
(Алма)

* Җир астында җиз бүкән,
Һәр көн ашыйсың, иркәм.
(Бәрәңге)

* Туп түгел — түгәрәк,
Күсе түгел — койрыклы.
(Чөгендер)

* Кызыл төймә таптым,
Авызыма каптым.
(Җиләк)

| | |
|---|---|
| **Туп кайда?**<br>Санамыш ярдәмендә уенны алып баручы сайлана. Балалар түгәрәккә басалар. Алып баручы уртада басып тора. Уйнаучылар, алып баручыга сизелмәслек итеп, арттан туп бирешәләр. Әгәр алып баручы тупның кемдә икәнен сизсә, аның янына килеп: «Кулларыңны күрсәт», – ди. Әлеге бала, учларын өскә каратып, кулларын югары күтәрә. Әгәр аның кулында туп булса (яки ул тупны төшереп җибәрсә), уен тәмам була. Әгәр туп<br>анда булмаса, ул кулларын яңадан артка куя, һәм уен дәвам итә. Туп белән 2–3 бала тотылгач, алып баручы алышына. | |
| **Тупны җибәрмә!**<br>Балалар, бер-берсенә кул сузарлык ара калдырып, түгәрәккә тезеләләр дә кулларын артка куеп, җилкә киңлегендә аякларын аерып басалар. Әйдәүче түгәрәк уртасына керә һәм тупны кайсы да булса бер уйнаучының аяк арасыннан тәгәрәтеп җибәрергә тырыша. Туп үзенә таба тәгәрәп килгән бала, аякларын тиз генә янәшә куеп, аны аяклары арасыннан чыгармаска тиеш. Тупны аяк арасыннан үткәргән бала түгәрәктән<br>бер адым артка китә. 2–3 бала тупны аяклары арасыннан<br>җибәргәч, уен тәмамланган санала. | |



# Исәнме, Яңа ел!

*Әти-әниләр өчен кулланма(6-7 яшь)*

**Һай, Кыш бабай**

Кемнең кигән киемнәре
Кем соң безгә шундый
ямьле
Энҗе кар бөртекләре? Яңа
ел алып килә? Кемнең
көмеш күк сакалы,
Матур-матур капчыкларга
Чәчләре, керфекләре?
Күчтәнәч салып килә?
Ә дигәнче үсте бабай —
Үзебездән дә биек.
Эчкә сыймый шатлыгыбыз
—
Киттек тирәли биеп.
Чаңгы-чанада шуарга
Булды шома тавыбыз.
Кем безгә аны ясаган,
Кем икән ул, табыгыз...
*Җәвад Тәрҗеманов*

| | |
|---|---|
| **Табышмаклар**<br><br>а) Елга ул тик бер килә,<br>Ул килсә, җир гөр килә.<br>Яшел чыршы әйләнә<br>Якты заллар күркенә. (Яңа ел)<br>б) Кыш бабайның юлдашы,<br>Аның белән гел бергә.<br>Шуңа аны җәй көне<br>Мөмкин түгел күрергә.<br>Җәй көне ул бөтенләй<br>Мөмкин хәтта эрергә,<br>Суга әверелергә. (Кар кызы)<br><br>в) Килә бары кыш җиткәч,<br>Иске ел үтеп киткәч.<br>Үзе белән һәрвакыт<br>Яңа ел алып килә.<br>Бүләк тулы капчыгын<br>Иңенә салып килә. (Кыш бабай) | |
| **Әйберне сакла!**<br>Балалар, аякларын аерып басып, кулларын артка куйган хәлдә, түгәрәккә тезеләләр. Бер бала түгәрәкнең уртасында тора. Һәр баланың алдында нинди дә булса берәр уенчык ята. Әйдәүче балалар алдындагы уенчыкны алырга тырыша, ә балалар ул килә башлагач чүгәлиләр дә аны куллары белән каплыйлар. Әйдәүче читкә китү белән торып басалар һәм кулларын артка куялар. Уенчыгын алдырган бала түгәрәктән арткарак чигенеп китә (уенчыгын саклап кала алса, кире урынына кайта). 2–3 бала әйберен алдыргач, яңа әйдәүче сайлана. Уен кабатлана. | |

| **Буш урын**<br>Уйнаучылар, кулга-кул тотынышып, түгәрәккә тезеләләр. Балалардан берсе әйдәүче булып сайлана, ул, кулына яулык алып, түгәрәкнең тышкы ягына чыга. Калган балалар, түгәрәкләнеп, идәнгә утыралар. Әйдәүче бала түгәрәкнең тышкы ягында йөри һәм берәр баланың җилкәсенә кагыла. Әлеге бала тиз генә урыныннан торып, әйдәүчегә каршы түгәрәк буйлап (уң якка таба) йөгереп китә. Әйдәүче, буш урынны алдан алып калырга теләп, теге баланыә каршысына йөгерә. Бушаган урынга кем беренче килеп җитсә, шул утырып кала, ә урынсыз калган бала әйдәүче була. | |
|---|---|
| | |



# ***Кыш***

***Әти-әниләр өчен кулланма(6-7 яшь)***

**Тизәйткеч «Шуа-шуа шомара».**
Чаңгычының чаңгысы
Шуа-шуа шомара.
Чаңгың шомарсын дисәң,
Кирәк ешрак шуарга.
Шаһидәнең чаңгысы
Шома әнә шуңарга

## ***Табышмаклар***

Урамнарны агарта,
Бар дөньяны яңарта.
Сафландыра кешене,
Ничек аның исеме?
(Кыш)

**Сынамышлар «Халык әйтсә – хак әйтә».**

а) Кыш бәс, томан булса, җәй иген уңа.
б) Кыш карсыз булса, җәй ярлы була.
в) Кар калын булса, ашлык уңар.
г) Каз аягын күтәреп торса, салкын булыр.
д) Төтен җиргә төшсә, кышын кар явар.
е) Кояш бик ерakta булып күренсә, салкын булыр.
ж) Тау башларында кар күп булса, җиләк күп булыр.

Шигырьләр

**Кыш килде**
Килеп җитте кыш та.
Ай-яй, салкын тышта...
Өч ай торыр торса,
Аның гомере кыска...
Тәңкә карлар сипкән,
Җирне ап-ак иткән;
Чыршы, каен, имән
Кардан чикмән кигән.
Саф һавага чыгып,
Таудан чана шуып,
Кышның салкыннарын
Җибәрәбез, куып.
Бари Рәхмәт

**Буранда**
Беркем чыкмый урамга,
Буранлы көн булганга.
Буран ала бөтереп,
Салкын ала өттереп!
Кошлар гына һавада
Чайкалалар һаман да.
Рәхәтләнеп очарга
Бик кыендыр кошларга.
Р.Миңнуллин.

**Сүзле-хәрәкәтле уен «Кышкы паркта».**
Кышкы паркка килдек,
Матур урыннар күрдек.
Тун кигән каен уңда,
Ямь-яшел чыршы – сулда.
Кар бөртекләре оча,
Әйләнеп, җирне коча.
Кызылтүшләр очалар,
Бигрәк матур алар.
Паркта рәхәт булса да,
Өйгә кайтыйк, балалар.

| | |
|---|---|
| **Хәрәкәтле уеннар**<br>**Чаналарга!**<br>Чаналарны мәйданчыкның бер ягына урнаштыралар. Аларның саны уйнаучылардан бергә кимрәк булырга тиеш. Мәйданчыкның икенче каршында балалар йөгереп йөриләр, әйләнәләр, сикергә-лиләр. Тәрбияче: «Чаналарга!»- дип сигнал бирә, балалар чана-ларга таба йөгерәләр һәм тиз генә берәр чанага утыралар. Иң соң-гы килгән бала урынсыз кала.<br>**Кар бөртекләре җыю»**<br>Бүлмә идәненә кар бөртекләре сибелә. Уенда ике бала катна- ша. Аларга матур тартма бирелә. Тәрбияче сигналы буенча, ба- лалар кар бөртекләрен җыеп, тартмаларга салалар. Алдан кайсы җыеп бетерсә, шул бала җиңүче була. | |



# Мин сәламәт булып үсәм

*Әти-әниләр өчен кулланма (6-7 яшь)*

***Мәкальләр***

а) Саулык-сәламәтлек – зур байлык.
б) Саф һава – тәнгә дәва.
в) Сакланган – саулыкка туйган.
г) Чирнең тиюе тиз, ә китүе озак.
д) Чисталык – сәламәтлек билгесе.

***Табышмаклар***

а) Ипи түгел, су түгел,
Авыр түгел, аз түгел,
Ансыз яшәү мөмкин түгел.
(Һава)

б) Иртә торгач кулыңа ал,
Миннән башла эшеңне.
Паста белән мин истартам
Ап-ак итеп тешеңне. (Теш щёткасы)

в) Тешләре күп – ашамый,
Минсез эшен башламый.
(Тарак)

д) Исе юк, төсе юк,
Аннан башка тормыш юк.
(Су)

| | |
|---|---|
| **Җырлы-биюле уен «Түгәрәк алан»**<br>Балалар кулга-кул тотынышып түгәрәктә такмак әйтеп йөриләр.<br>Бу аланда чәчәкләр күп,<br>Кыймыйм ләкин өзәргә.<br>Әминә, Гөлфия,<br>Әйдә әле биергә.<br>Бу аланда чәчәкләр күп,<br>Без аларга тимибез.<br>Лилия, Гөлия,<br>Әйдә бергә биибез. | |
| **Хәрәкәтле уеннар**<br>**Туп кайда?**<br>Санамыш ярдәмендә уенны алып баручы сайлана. Балалар түгәрәккә баса-лар. Алып баручы уртада басып тора. Уйнаучылар, алып баручыга сизелмәс-лек итеп, арттан туп бирешәләр. Әгәр алып баручы тупның кемдә икәнен сизсә, аның янына килеп: «Кулларыңны күрсәт», – ди. Әлеге бала, учларын өскә каратып, кулларын югары күтәрә. Әгәр аның кулында туп булса (яки ул тупны төшереп җибәрсә), уен тәмам була. Әгәр туп анда булмаса, ул кулла-рын яңадан артка куя, һәм уен дәвам итә. Туп белән 2–3 бала тотылгач, алып баручы алышына. | |



# *Кеше һәм әйләнә-тирә дөнья*

***Әти-әниләр өчен кулланма(6-7 яшь)***

**«Безгә тынычлык кирәк».**
Шаулый урман, гөрли болын,
Яфрак яра тал-тирәк.
Яшел бакча төзү өчен,
Безгә тынычлык кирәк.
Тормышны, җирне яңарту –
Безнең беренче теләк,
Зур заводлар салу өчен,
Безгә тынычлык кирәк.

Тигез хокук, ирек белән
Ходай биргән безгә гомер.
Сәламәт бул, шатлык белән
Җирдә яшә син бик матур.

Ә.Ерикәй

| *Мәкальләр* | |
|---|---|
| * Рәхмәт кемгә дә рәхәт.<br>* Кош — канаты белән, кеше дуслары белән көчле.<br>* Дустың булмаса — эзлә, тапсаң — югалтма.<br>* Кешегә иң кирәге — ягымлы чырай, җылы сүз.<br>* Татлы тел аюны да биетә.<br>* Теле татлының дусты күп. | |

| **Шигырьләр** | |
|---|---|
| **Әйдә, танышабыз**<br><br>Йә, әйдә, танышабыз,<br>Кулга-кул бирешәбез,<br>Исемне әйтешәбез,<br>Кул кысып күрешәбез.<br>Киң итеп елмай миңа,<br>Мин дә елмаям сиңа.<br>Туры итеп караштык,<br>Менә шулай таныштык.<br>Вәсимә Хәйруллина | |

| | |
|---|---|
| **Үстерешле уеннар**<br>**Минем кебек эшлә**<br>Һәр уенчыга 8әр санау таякчыгы бирелә. Алып баручы нинди дә булса ирекле корылма ясый. Бер-ике секундка балаларга күрсәтеп ала һәм кәгазь белән каплап куя. Янындагы бала хәтерләп калуы буенча шундый ук фигураны төзергә тиеш. Соңыннан уенчылар урыннарын алмашып уйныйлар. Әгәр уен уңышлы килеп чыкса, санау таякчыкларын арттырып (12-15кә кадәр), уенны катлауландырырга була.<br>**Тиз әйт**<br>Балаларга тәрбияче хәрефләр күрсәтә, ә алалар шул хәрефкә баашланган дару үләнен атый бара. Уенда 8-10 бала катнаша. Алар бертигез булып рәткә тезеләләр. Кайсы бала дару үләнен дөрес атый, шул бер адым алга чыга. Кайсы бала иң күп дару үләнен атый һәм барыннан да алда була, шул җиңүче дип санала. | |
| **Хәрәкәтле уеннар**<br>Хәрәкәтле уен «Бабай һәм оныклар».<br>Бер бала – бабай, калганнары – оныклар; бабай өйдә уты- ра, ә оныклар өйдән читтәрәк нәрсә эшләячәкләре турында сөйләшәләр. Мәсәлән: бакчада җир казыдык, оекбаш бәйләдек, кер юдык һ.б. Аннары бабай янына киләләр, бабай алардан: «Сез кайда булдыгыз?»- дип сорый. Балалар: «өйдә», «урманда», «бак-чада» һ.б. дип җавап бирәләр. Бабай: «Сез анда нишләдегез?»- ди. Балалар бергәләп бертөрле хәрәкәт белән нәрсә эшләгәннәрен күрсәтәләр. Бабай белергә тиеш. Дөрес җавап әйтелгәч, балалар йөгерәләр, бабай аларны куа. Беренче тотылган бала бабай була. | |



# *Туган тел атнасы*

***Әти-әниләр өчен кулланма(6-7 яшь)***

## *Җырлар, юаткычлар, эндәшләр*

* Ябалак, ябалак,
Йөрмә, чеби сагалап.
Чебиемне бирмәм,
Күземә күренмә, кош

Камка түти, кач, кач,
Алтын капкаң ач, ач.
Анаң салма пешерә,
Атаң ашап бетерә.

## *Мәкальләр*

Мәкаль-уен «Башын әйтәм, ахырын әйт!»
а) Кош канаты белән, ... (кеше дуслары белән көчле).
б) Дустың булмаса – эзлә, тапсаң – ... (югалтма).
в) Ялгыз агачны җил ... (сындыра).
г) Күмәк күтәрсә – ... (күлне күчерер)
д) Иртәгә үкенерлек эшне ... (бүген эшләмә).
е) Терсәкне бик тешләр идең дә, ... (тешләп булмый).
ж) Эш үткәч үкенүдә ... (файда юк).

**Шигырьләр**

**Х.Халиков. «Сөйләшсәләр безнеңчә ...».**

Җирдә нинди илләр юк,
Нинди генә телләр юк
...
Һәркем сөйли үзенчә,
Сөйләшсәләр безнеңчә
Эреп китәм, май кебек,
Йөзем тулган ай кебек
Яктырганнан-яктыра.
Күңелдә таң аттыра
Балдан да татлы телем,
Нәфис һәм затлы телем.

**Җырлы уен «Агыйдел».**

Балалар бер-бер артлы басалар. Парсыз калган бала алга чыга.

Агыйдел суларында
Ак чиләгем күмелде.
Әйдә, дустым, безнең якка,
Безнең яклар күңелле.

Кушымтаны җырлаганда балалар, кулларын өскә күтәреп, «капка» ясыйлар.

Зәңгәр чәчәк җыя-җыя,
Зәңгәрләттем кулымны.
Бергә-бергә уйныйк әле,
Бир, дускаем, кулыңны.

Парсыз калган бала капкалардан чыга һәм үзенә ошаган баланы сайлый. Уен дәвам итә

| | |
|---|---|
| **Хәрәкәтле уеннар**<br>**Чуваш халкының хәрәкәтле уены «Тили-рам, бездән сезгә кем кирәк?»**<br>Уенда ике команда катнаша. Ике команда бер-берсенә кара-каршы басып тора. Беренче команда бергәләп әйтә: «Тили-рам, тили-рам?» (Сезгә кем, сезгә кем?) Ә икенче команда кулга-кул тотынып, беренче командадан бер уенчының исемен әйтә. Исем әйтелгән бала икенче якка йөгереп чыга. Аннан рольләрне алыштыралар. Ахырдан командалар, бер-берсе белән канат ярдәмендә тартышалар. | |



# Ватанны саклаучылар көне

*Әти-әниләр өчен кулланма (6-7 яшь)*

## *Мәкальләр*

* Әти-әни — чын дустым, дус-ишләрем — юлдашым.
* Ата-анасына игелек күрсәтмәгән,  олыгайгач, үзе дә игелек күрмәс.
* Әткәй — шикәр, әнкәй — бал.
* Бердәм өйдә бәрәкәт була.
* Яктылык — кояш янында, яхшылык — ана янында.
* Икмәкнең валчыгы да бездән олы, коеп ашама.
* Туган илем — туган өем.
* Дустың булмаса — эзлә, тапсаң — югалтма.
* Кешегә иң кирәге — ягымлы чырай, җылы сүз.
* Татлы тел аюны да биетә.
* Теле татлының дусты күп.
* Тыйнаклык кешене бизи.
* Бер ялганласаң, икенче дөрес сүзеңә дә ышанмаслар.

| | |
|---|---|
| **Шигырьләр**<br>**Батыр һөнәр**<br>Батыр һөнәр бар җирдә –<br>Җирне, илне саклаучы.<br>Сине, мине - һәркемне<br>Дошманнардан яклаучы.<br>Генералмы, майормы,<br>Капитанмы, йә сержант –<br>Барсының да исеме<br>Дөньяда бер ул – солдат.<br><br>Ватанны саклаучылар<br>Аямыйлар үз-үзен;<br>Беләкле, йөрәклеләр,<br>Ихтыярлы һәм түзем.<br>Саклап Ватанны, безне<br>Хәтәр сугыш утыннан,<br>Батыр һөнәр иясе<br>Китә торган йортыннан<br>Вәсимә Хәйруллина | |
| **Үстерешле уеннар**<br>**Ак аю**<br>Җиргә диаметры 4-5 м булган түгәрәк сызыла. Уйнаучылар түгәрәк эченә кереп басалар. Санамыш ярдәмендә ике бала “ак аю” итеп билгеләнә. Алар түгәрәкнең тышкы ягында кала. “Аю килә” дигән сигнал булуга, “аюлар”, кулга-кул тотынышып, түгәрәк эченә керәләр һәм балаларны эләктерергә тырышалар. Һәр тотылган бала уеннан чыга бара. Уен ахырында “аюларга” тоттырмаган бер генә бала кала. Ул җиңүче була. | |

| | |
|---|---|
| **Хәрәкәтле уен «Кем тизрәк үзенең танкына барып җитә?»**<br>Уен өчен ике кыска таяк кирәк. Таякка 8 – 10 метр озынлыктагы бау бәйләнә. Бауның уртасына уенчык танк эленә. Ике уенчы таякларны алып, бауны тарттырып кара-каршы басалар. Уйнаучылар тәрбияче сигналы буенча, кулларында тиз-тиз таякны әйләндереп, бауны чорныйлар һәм әкрен генә бер-берсенә каршы баралар. Бауны уртага кадәр беренче булып чорнаган бала җиңүче була. | |



# *8 Март – әни бәйрәме*

*Әти-әниләр өчен кулланма(6-7 яшь)*

**Бүген әниләр бәйрәме**

Нигә бүген бөтен жирдә
Чәчәкләр балкый бездә,
Нигә кояш көлеп карый, —
Беләбез һәммәбез дә.
Бүген — әниләр бәйрәме,
Бүген жирдә тантана.
Кояш шуңа көлә бүген,
Гөлләр шуңа шатлана.
Әниләрнең бәйрәменә
Куана шулай алар.
Әниләрне котлый бүген
Жирдә барлык балалар.
Мин дә котлыйм, энкәм, сине,
Теләгем бар минем дә:
Мәңге шулай кояш кебек
Балкы күңел күгемдә.

Резеда Вәлиева

| | |
|---|---|
| **Шигырьләр**<br>**Әниләр бәйрәме**<br>Кояш көлә, мин елмаям,<br>8 нче Март бүген.<br>Бүген әниләр бәйрәме,<br>Шуңа күңелем шат минем.<br>Кайсын юам, кайсын җыям,<br>Чиста булсын, ак булсын.<br>Әниләрнең күңеледәй<br>Бөтен нәрсә пакь булсын.<br>— Бәйрәм бүген, бәйрәм! — диеп,<br>Бар дөнья көлеп торсын.<br>Әни бәйрәме икәнен<br>Әти дә белеп торсын,<br>Әти дә көлеп торсын!<br>Саҗидә Сөләйманова | |
| **Җырлы биюле уен “Гөл утыртканда”**<br>Балалар түгәрәкләнеп басалар. Уртада башына кызыл чәчәк-ләр белән бизәлгән тәкыя кигән бер бала чүгәләп утыра. Аның өстенә карарак төстәге җәймә ябалар. Әлеге бала ти-рәсендә берничә бала гөл утырткан хәрәкәтләр ясыйлар. Түгәрәктәге барлык башка балалар түбәндәге җырны җырлыйлар:<br>Балчык йомшартып утыртамын гөл,<br>Шытып, яшәреп чыгар әле ул.<br>Көн саен карап, мин сибәрмен су,<br>Чәчкә атар ул кызылсу-алсу.<br>Канатын җәеп, аңа кунар бер былбыл.<br>Моңланып сайрар: – Син, дип, матур гөл!<br>Җыр тәмам булганнан соң, җәймә астыннан «гөл» күтәрелә.<br>Сандугач киемендәге бер бала түгәрәккә кереп җырлый:<br>Ай-яй, матур гөл, ямьле, ал-кызыл.<br>Сөямен, сиңа гашыйк мин, былбыл.<br>Җырлар тезәмен сиңа, ал гөлем, Син үскәндә тик, ямьле бу илем. | |

| | |
|---|---|
| **Хәрәкәтле уеннар**<br>**Туп кайда?**<br>Санамыш ярдәмендә уенны алып баручы сайлана. Балалар түгәрәккә басалар. Алып баручы уртада басып тора. Уйнаучылар, алып баручыга сизелмәслек итеп, арттан туп бирешәләр. Әгәр алып баручы тупның кемдә икәнен сизсә, аның янына килеп: «Кулларыңны күрсәт», – ди. Әлеге бала, учларын өскә каратып, кулларын югары күтәрә. Әгәр аның кулында туп булса (яки ул тупны төшереп җибәрсә), уен тәмам була. Әгәр туп анда булмаса, ул кулларын яңадан артка куя, һәм уен дәвам итә. Туп белән 2–3 бала тотылгач, алып баручы алышына. | |



# Кеше һәм математика

*Әти-әниләр өчен кулланма(6-7 яшь)*

## *Санамышлар*

* Әнә тора бер чыпчык,
Менә тора бер чыпчык,
Артык булсаң, очып
чык!

* Чар, чар, чыпчыклар,
Бирсәгез лә орчыклар.
Анда чык, монда чык,
Саубуллаш та моннан
чык.

* Кулда —уймак,
Табада — коймак,
Мичтә — бәлеш,
Ал да ябыш.

* Әке, бәке,
Кыек сәке,
Эремчек.
Син калып тор,
Ә син чык.

| | |
|---|---|
| **Шигырьләр**<br>Менә сиңа уң кулым.<br>Менә сиңа сул кулым<br>Уң кулым, сул кулым.<br>Менә сиңа куш кулым.<br><br>**Беләсеңме?**<br>Йөз чикләвек җыйдым мин,<br>Биштән берен ашадым.<br>Калганының яртысын<br>Кортлы булгач ташладым.<br>Энем белән сеңелемә<br>Бүлеп бирдем калганын.<br>Беләсеңме аларның<br>Ничәшәрне алганын? (энесе белән сеңлесенә 20шәр чикләвек биргән) | |
| **Ял минуты**<br>**Без инде хәзер зурлар**<br><br>Без инде хәзер зурлар,<br>Күп эшли безнең куллар.<br><br>Без идән дә юабыз,<br>Без керләр дә уабыз,<br>Гөлләргә су сибәбез.<br><br>Менә шундый уңган без,<br>Менә шундый булган без.<br><br>аяк очларына басып, кулларын югары күтәрәләр, кулларын төрле якка хәрәкәтләндерәләр<br>иелеп, идән юу хәрәкәтләре ясыйлар, куллар белән кер «уалар», гөлгә су сибү хәрәкәте күрсәтәләр<br>аяк очларына басып, түгәрәктә әйләнәләр | |

| | |
|---|---|
| **Хәрәкәтле уеннар**<br>**Күз бәйләш**<br>Уйнаучылар түгәрәкләнеп тезеләләр, түгәрәкнең уртасында ике бала басып тора. Аларның берсенең күзен бәйлиләр, ә икенчесенә кечкенә кыңгырау бирәләр. Беренче бала кыңгырау тавышы буенча иптәшен тотарга тырыша, әђ икенчесе ничек булса да тоттырмаска тырыша. Ул тотылганнан соң, түгәрәк уртасына башка балалар керәләр.<br>**Узышчылар**<br>Балалар парлашып, бер-бер артлы тезелеп басалар. Уйна-учылардан 20–25 м ераклыкта сызык үткәрелә яисә бу урын флаглар белән билгеләнә. Уйнаучылар барысы бергә: «Бер, ике, өч!» – дип кычкыралар. Шуннан соң беренче булып басып торган ике бала флагларга кадәр йөгереп барып, кире йөгереп әйләнеп кайталар. Икесе дә бер-берсен узарга тырыша. Кире әйләнеп кайткан балалар артка басалар, аннан соң икенче пар йөгерә. | |



# *Нәзүрүз җитми яз булмый*

***Әти-әниләр өчен кулланма(6-7 яшь)***

**Нәүрүз**

Әнә яз яшелләнә,

Җир-анабыз гөлләнә,

Бозны тишә ак чәчәк,

Көнгә бага саф чәчәк! Бүген көн тиң төннәргә,

Урын юк һич көнләргә,

Без дә тиң, без дә тигез!

—Мөбарәк Нәүрүз! — дибез.

Әхмәт Гадел

| | |
|---|---|
| **Шигырьләр**<br><br>**Карга боткасы**<br>Җиребезгә язлар килгәч,<br>Кошлар кайткач еракта н,<br>«Карга боткасы» пешергән<br>Халкыбыз чын йөрәктән.<br>Бу бәйрәм безнең көннәргә<br>Килгән, гасырлар үтеп.<br>Каргалар да, без дә аны<br>Һәр ел алабыз көтеп.<br>Йолдыз | |
| **Җырлы биюле уен "Сукыр тәкә"**<br>Бер баланы, күзен юәйләп, уртага бастыралар. Ул – "Сукыр тәкә". Калган балалар кырыйда җырлыйлар:<br>Сукыр тәкә йөгерә,<br>Күрми ул бернәрсә дә.<br>Йөгермичә нишләсен,<br>Тота алмый берсен дә.<br>Җыр беткәч, балалар сукыр тәкәгә якын килеп, кагылып китәләр. Сукыр тәкә куа. Кемне дә булса тотса, тотылган бала "сукыр тәкә" була.<br>Уен шулай дәвам итә. | |

| | |
|---|---|
| **Хәрәкәтле уеннар**<br>**Яулык алыш**<br>Бу уен күбесенчә кыз балалар тарафыннан уйнала. Кызлар бер урынга түгәрәкләнеп басалар да бер кешене яулык җыючы итеп сайлап куялар. Ул уртага чыгып баса да:<br>Талым, талым, талчыбык, уртасында бал чыбык,<br>Ал яулык, гөл яулык, бир син миңа бер яулык, —<br>дип такмаклый-такмаклый, барлык кызлардан да яулык җыеп чыга. Җыеп бетергәч, яулык хуҗаларына бирәм-бирәм җәза бирелә. Җәзадан соң уен тагын яңадан башлана. | |



# *Кошлар безнең дусларыбыз*

*Әти-әниләр өчен кулланма (6-7 яшь)*

## *Мәкальләр һәм әйтемнәр*

а) Кош оясын туздырма, башың авыртыр.
б) Кошларга таш атма, күзең сукыраер.
в) Сыерчыкларга оя ясa, эшең уңар.
г) Кош йомыркаларын ватма, күз яшеңне түгәрсең.

**Табышмаклар**

а) Көләч түтәй гөлдерәп,
Кызыл читек, күк күлмәк.
Җим сибәбез күргәчтен
Бу кем була? ... (Күгәрчен)

б) Җәй шакылдый бу чүкеч,
Кыш шакылдый бу чүкеч.
Ничек чыдый бу чүкеч?
(Тукран)

в) Чырык-чырык
чыркылдый,
Бер җиргә дә ул китми.
Безнең белән дус яши,
Әйтегезче, ул ни? (Чыпчык)

**Сүзле-хәрәкәтле уен «Әйтеп бирче, үскәнем».**

Балалар түгәрәк ясап басалар. Бер бала санамыш ярдәмендә сайланып уртага чыгарыла, калганнары күмәк җырлап әйләнәләр. Уртадагы балага төрле эшләр кушалар.
Эшләр кошлар тематикасына багышлана.

- Әйтеп бирче, үскәнем, нинди төстә каргалар?
- Кара төстә, кара төстә, чем-кара ул каргалар.
- Әйтеп бирче, үскәнем, нинди төстә сыерчыклар?
- Яшькелт, кара яшькелт - бу була сыерчыклар.

**Санамышлар**

*Чар, чар, чыпчыклар,
Бирсәгез лә орчыклар.
Анда чык, монда чык,
Саубуллаш та моннан чык.

*Карга, чыпчык,
Берең кал да,
Берең чык.

* Каенда – карга,
Имәндә – чыпчык,
Җирдә – елан,
Һавада – кош,
Бар син дә оч.

*Әнә тора бер чыпчык,
Менә тора бер чыпчык,
Артык булсаң, очып чык!

# Хәрәкәтле уеннар

**Җырлы-биюле уен «Ике аккош».**

Балалар түгәрәккә басалар, ике бала уртада кала. Алар аккошлар була. Балалар җырлап әйләнәләр: Очалар ике аккош, алар кечкенәләр.

Кара кошкайларым, кара күзкәйләрем,
Алар бара торгач, утырып ял итәләр.
Кара кошкайларым, кара күзкәйләрем,
Алар бара торгач, салют бирешәләр.
Кара кошкайларым, кара күзкәйләрем,
Алар бара торгач, иптәш сайлашалар,
Кара кошкайларым, кара күзкәйләрем.

Аккошлар түгәрәктән иптәшләрен сайлап алып, уртага чакыралар, урыннарын алышалар. Уен шулай дәвам итә.



# *Яз*

***Әти-әниләр өчен кулланма(6-7 яшь)***

***Эндәшләр***

**«Сыерчык».**
Сыерчык, сыерчык,
Күк күлмәгең киеп чык;
Үзеңнеке булмаса,
Атаңныкын киеп чык!
Атаңныкы булмаса,
Анаңныкын киеп чык;
Анаңныкы булмаса,
Бабаңныкын киеп чык

**Мәкальләр**

а) Яз яме чәчкә белән, көз яме көлтә белән.
б) Язның байлыгы – кояш, көзнең байлыгы – уңыш.
в) Язгы көн ел туйдыра.

## Шигырьләр

### Яз килә

Көннәр аяз, күктә алсу
Нур сибеп, кояш көлә.
Җиргә тама көмеш тамчы —
Сагынып көткән яз килә.
Әйтегезче: кайсы вакыт
Яздагыдан ямьлерәк?
Кыш айларын да яратам,
Әмма яз күңеллерәк

Мөнир Мазунов

## Санамышлар

*Чар, чар, чыпчыклар,
Бирсәгез лә орчыклар.
Анда чык, монда чык,
Саубуллаш та моннан чык.

*Карга, чыпчык,
Берең кал да,
Берең чык.

* Тәрәз каршына
Килгән бер чыпчык
— Чык әле, ди, чык!

*Әнә тора бер чыпчык,
Менә тора бер чыпчык,
Артык булсаң, очып чык!

| **Хәрәкәтле уен «Тилгән һәм тавык”**<br>Уен мәйданчыгының бер башында җиргә түгәрәк сызыла. Ул — «тилгән оясы». Уенда катнашучыларның берсе — «тилгән», икенчесе «тавык» итеп билгеләнә. Калган балалар «чебиләр» булалар. «Чебиләр» бер-берләренә тотынып, «тавык» артына тезелеп басалар. Уенны алып баручы «тилгән килә» дип сигнал бирә. «Тилгән» оясыннан чыга да колоннада соңгы булып басып торучы «чеби»не тотарга тырыша. «Тавык», «канатларын җәеп», балаларын саклый. Ул «тилгән» кайсы якка ташланса, шунда «тилгән»гә каршы чыга. Бу вакытта «чебиләр», бер-берләреннән аерылмыйча, «тавык» артыннан ияреп йөриләр, соңгы булып басып торучы «чеби»не тоттырмаска тырыша-лар. Әгәр «тилгән» иң арттагы баланы тартып ала алса, ул аны үз оясына алып китә. | |
|---|---|



# Җиңү көне

*Әти-әниләр өчен кулланма(6-7 яшь)*

***Татар халык авыз иҗаты***

***Тел көрмәкләндергечләр***

* Ваттым мичкә, яктым мичкә,
Бер мичкәне бер мичкә.
Ярый сыйды мичкә мичкә,
Ул да житте бер кичкә.

* Күпер башында күп күркә, күп күркәгә кирәк күп көрпә.

* Казандагы суны кайнарландыралсаң кайнарландыр.

**Мәкальләр**

а) Яз яме чәчкә белән, көз яме көлтә белән.
б) Язның байлыгы – кояш, көзнең байлыгы – уңыш.
в) Язгы көн ел туйдыра.

## Шигырьләр

***Татарстан байрагы***

Җилфер-җилфер итә байрагыбыз,
Ниләр сөйли соң ул җилләргә? —
Көрәшүче татар халкыннан ул
Сәлам әйтә азат илләргә...
Өч төс балкый безнең бу байракта:
Ак төс — безнең намус төсебез.
Яшел төсе — безнең яшәү төсе,
Кызылында чагыла көчебез.
Җилфер-җилфер итә безнең байрак,
Элеп куйдык аны биеккә.
Дөнья безнең шушы байрак аша
Омтылышны күрсен иреккә.

Фәнис Яруллин

## Санамышлар

*Чар, чар, чыпчыклар,
Бирсәгез лә орчыклар.
Анда чык, монда чык,
Саубуллаш та моннан чык.

*Карга, чыпчык,
Берең кал да,
Берең чык.

* Тәрәз каршына
Килгән бер чыпчык
— Чык әле, ди, чык!

*Әнә тора бер чыпчык,
Менә тора бер чыпчык,
Артык булсаң, очып чык!

| **Җырлы-хәрәкәтле уен «Там, там, тамчы там».**<br>Уенчылар пар-пар булып, кулга-кул тотынып, бер-бер артлы басалар. Алар күмәкләшеп, хәрәкәтләр ясап, җырлыйлар.<br>Там, там, тамчы, там,<br>Тамганыңны яратам.<br>Тамган тамчыларга карап,<br>Мин җырларга яратам.<br>Тамчы тама, тамчы тама,<br>Тамчы тама түгелме?<br>Тамчы тамса, матур язлар<br>Килеп җитә түгелме? | |
| --- | --- |